**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПУЧЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423730, Актаныш районы, Пучы авылы, Киров ур., 2А нче йорт.
тел. 3-44-51.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ПОИСЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
423730, Актанышский район,
село Поисево, ул. Кирова, дом 2А.
Тел. 3-44-51.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.04.2026года № 9

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы

«Пучы авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24,28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Пучы авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Пучы авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2026 елның 20 апрелендә ачык тыңлаулар билгеләргә

2. Ачык тыңлаулар уздыру урыны итеп билгеләргә:

Пучы авылы, Совет урам, 21 йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы, үткәрү вакыты 13:00 сәгатьтэ;

Энэк авылы, Ш.Шаймиев урамы 8 йорты адресу буенча урнашкан Энэк мәдәният йорты бинасы, үткәрү вакыты 15:00 сэгатьтэ.

3. Ачык тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Пучы авылы, Киров урам, 2А йорт.

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтындагы "авыл җирлекләре" бүлегендә: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

Пучы авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе А.Р. Гилемов